ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08. 05. 2020 Олы Кайбыч ав. № 234

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга
туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары
яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм
2020 елның II кварталына салым салынырга
тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (Россия Төзелеш министрлыгы) «2020 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 13 мартындагы 122/пр номерлы боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның II кварталында гражданнарны аз keremле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен-1 749 792 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен-2 227 008 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен-2 863 296 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен-3 817 728 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 4 772 160 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен-5 726 592 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 681 024 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 635 456 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме, (1 нче кушымта) хисап нигезендә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 18740,05 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 11925,49 сум;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 10221,85 сум.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 е. 08.05. 234 номерлы
карарына кушымта

2020 елның II кварталына һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмен билгеләү МЕТОДИКАсы

1. Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ, монда

СЖ - базар бәясенең исәп күрсәткече яисә мөлкәт хакының чиге;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - РФ төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап бәясе (2020 елның икенче кварталына-53024 сум).

а) ) ялгыз яшәүче гражданга:

СЖ = 33 х 53 024 = 1 749 792 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 42 х 53 024 = 2 227 008 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 3 х 53 024 = 2 863 296 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 4 х 53 024 = 3 817 728 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 5 х 53 024 = 4 772 160 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 6 х 53 024 = 5 726 592 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 7 х 53 024 = 6 681 024 сум

3) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 8 х 53 024 = 7 635 456 сум.

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күләме түбәндәгечә билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) - КП) / (0,3 х РС), монда

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күләме;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

ПС - бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма); («Татарстан Республикасы ипотека торак кредиты буенча агентлык» ААҖ буенча аена 10 % яисә аена 10/12).

КП - бөтен кредит срогы буенча кредит түләүләрнең гомуми саны (ай саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе чагыштырмасы;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

Торак урыны мәйданының уртача базар бәясе Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән 2020 елның II кварталына 53024 сум дип билгеләнгән.

1нче таблица

## Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күләмен исәпләү

| НП - торак урыны нормасы (кв. м) | СЖ - торак бинаны сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - 1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | кредит суммасы һәм фатир бәясе чагыштырмасы | җыелма айлык керем белән кредит буенча түләү чагыштырмасы | ПД – керемнең максималь күләме (сум) (кешегә) | Керемнең чик күрсәткече (сум) (гаиләгә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| | | | 53 024 | 10/12 | 180 | 0,7 | 0,3 | | |
| 33 | 1 749 792 | 1 | 53 024 | 0,83 | 180 | 0,7 | 0,3 | 18740,05 | 18740,05 |
| 42 | 2 227 008 | 2 | 53 024 | 0,83 | 180 | 0,7 | 0,6 | 11925,49 | 23850,98 |
| 54 | 2 863 296 | 3 | 53 024 | 0,83 | 180 | 0,7 | 0,9 | 10221,85 | 30665,54 |
| 72 | 3 817 728 | 4 | 53 024 | 0,83 | 180 | 0,7 | 1,2 | 10221,85 | 40887,39 |
| 90 | 4 772 160 | 5 | 53 024 | 0,83 | 180 | 0,7 | 1,5 | 10221,85 | 51109,24 |
| 108 | 5 726 592 | 6 | 53 024 | 0,83 | 180 | 0,7 | 1,8 | 10221,85 | 61331,08 |
| 126 | 6 681 024 | 7 | 53 024 | 0,83 | 180 | 0,7 | 2,1 | 10221,85 | 71552,93 |
| 144 | 7 635 456 | 8 | 53 024 | 0,83 | 180 | 0,7 | 2,4 | 10221,85 | 81774,78 |